ШИМБӘ
16 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 13 (6735)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН өлкә һәм КАЗАН шәһәр КОМИТЕТЛАРЫ ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ,

Халыкка киң куллану товарларын күбрәк бирик!

Кашык сынды, җөрәк кирәк булды, чүлмәк ватылды—боларны кайдан алырга?

Мондый һәм моңа ошашлы, көндәлек тормышта кирәк була торган бик күп төрле киң куллану әйберләренең әллә кайдан читтән китерелүен көтеп яту һич тә дөрес түгел. Халык өчен киң куллану товарлары җирле чималдан шул урынның үзендә җитәрлек күләмдә җитештерелергә тиеш.

Урында булган барлык ресурсларны тулысынча мобилизацияләү, транспортны артык йөкләр ташудан мөмкин кадәр бушату буенча гаять әһәмиятле булган бу чарага партия һәм хөкүмәт сугышка кадәр дә бик зур игътибар биреп килә иде. Хәзерге сугыш шартларында исә җирле промышленностьны үстерү, җирле чимал базасында киң куллану товарларын күбрәк һәм күбрәк эшләп чыгару, фронт өчен корал коючы хезмәт ияләренең тормыш көнкүрештәге барлык ихтыяҗларын тоткарсыз үтәп тору бурычы—зур әһәмиятле политик бурыч булып әверелде.

Бу өлкәдәге тирән җаваплылыкны аңлаган урыннарда, хезмәт ияләренең сораулары белән җитди исәпләшеп, җитешсезлекләргә каршы кискен көрәш оештырып, киң куллану товарларын эшләп чыгаруда инициатива, тапкырлык, большевистик кыюлык күрсәткән урыннарда без яхшы нәтиҗәләргә ирешелүен күрәбез.

Мисалга Чистай шәһәрен алырга мөмкин. Узган елның өченче кварталында андагы күп санлы предприятиеләрдә һәм артельләрдә киң куллану товарлары эшләп чыгару планы үтәлмичә калган иде. Шәһәрнең партия, совет оешмалары бу мәсьәлә белән җитди рәвештә шөгыльләнә башлагач та хәл үзгәрде. Шәһәрдәге предприятиеләр һәм артельләр киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча дүртенче квартал планын 112 процентка, ә декабрь ае планын 118 процентка үтәделәр.

Ләкин, кызганычка каршы, барлык урыннарда да эш шулай яхшы тора дип әйтеп булмый әле. Республикабызның күп кенә районнарында үзләрендә булган чималдан киң куллану товарлары эшләп чыгару эше һаман да тиешенчә җайга салынып җитә алганы юк. Бу мәсьәлә район җитәкчеләренең игътибар үзәгендә тормавы нәтиҗәсендә җирле промышленность предприятиеләре, артельләр киң колач алып эшли алмыйлар, үсә алмыйлар, күп кенә районнарда бик реаль булган планнар да үтәлмичә кала. Мәсәлән, кашык, агач көрәк, естәл һ. б. кебек әйберләрне мул рәвештә җитештерү өчен Кызыл юл районында бөтен мөмкинлекләр бар. Чимал җитәрлек, эшче көчләр белән тәэмин ителгән артельләр, мастерскойлар бар. Бу өлкәдә эшне чын-чынлап намус белән оештырганда бик күп төрле киң куллану товарлары белән Кызыл юл районы үзен генә түгел, күрше районнарны да тәэмин итеп тора алыр иде. Хәлбуки анда эшләр бөтенләй киресенчә тора. Артельләр башында утыручылар эшлексезлек, булдыксызлык күрсәтәләр, эшчеләр арасында масса-агитация эшләрен, социалистик ярышны киң җәелдерү, хезмәт дисциплинасын ныгыту урынына, үзләре дисциплинасызлык күрсәтәләр, эшкә бармак аша карыйлар («21 нче МЮД» артеле—председателе Фәйзуллина, Молотов исемендәге артель—председателе Хәйруллин һ. б.). Артельләрдәге мондый җитешсезлекләрне район җитәкчеләре күрәләр, беләләр. Ләкин төлгә алып әйтерлек реаль чаралар күрмиләр. Шушындый хәл булганда бу районндагы артельләрнең узган ел производство программасын нибары 37,4 процентка гына үтәүләренә гаҗәпләнерлек һич тә урын калмый.

Чистайлылар, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярыш уңае белән, киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча үз өсләренә социалистик йөкләмәләр алдылар һәм казанлыларны ярышка чакырдылар. Аларның бу чакыруын казанлылар гына түгел, ә республикабыздагы барлык җирле промышленностьның һәм барлык системадагы артельләрнең работниклары да иштерләр һәм бу ярышка актив рәвештә кушылырлар дип ышанырга мөмкин.

МОЛОТОВ ШӘҺӘРЕ

ДЗЕРЖИНСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ЗАВОД ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ПАРТОРГЫ ИПТӘШ КАМОРОВКА

«Дзержинец» исемле истребитель эскадрильяләре төзүгә 1.500.000 сум акча җыйган Дзержинский исемендәге Ленин орденлы заводның эшчеләренә, эшче хатын-кызларына, инженер-техник работникларына һәм хезмәткәрләренә минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

ПИОНЕРЛАРГА ҺӘМ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

ТУЛА ӨЛКӘСЕ, БАБЫНИНО, УКУЧЫ ЕРМАКОВАГА
МОСКВА, СИБИРСКИЙ ПРОЕЗД, 2 нче ЙОРТ ИОСИФ, АНЯ ҺӘМ НАТАН РОГОВЛАРГА
НАХИЧЕВАНЬ АССР НЫҢ «ОРАХ» КОЛХОЗЫ, УКУЧЫ АЛИЗА МАРАЛ БӘЙРӘМ КЫЗЫНА
РЯЗАНЬ ӨЛКӘСЕ, КАРАБЛИНО, УКУЧЫ ВОЛОДЯ МИНАЕВКА

Кызыл Армия турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен рәхмәт Сезгә, яшь иптәшләр.

Укуда һәм җәмәгать эшендә Сезгә уңышлар телим.

И. СТАЛИН.

СЕБЕР ХӘРБИ ОКРУГЫ ГАСКӘРЛӘРЕ КОМАНДУЮЩИЕ ГЕНЕРАЛ-ЛЕЙТЕНАНТ МЕДВЕДЕВКА
СЕБЕР ХӘРБИ ОКРУГЫ ХӘРБИ СОВЕТЫ ЧЛЕНЫ ГЕНЕРАЛ-МАЙОР КОЛОБЯКОВКА
СЕБЕР ХӘРБИ ОКРУГЫ ПОЛИТУПРАВЛЕНИЕСЕ НАЧАЛЬНИГЫ ПОЛКОВНИК ЗАХАРЫЧЕВКА

Кызыл Армия өчен кораллар эшләүгә 7.446.000 сум акча җыйган Себер хәрби округы частьларының кызылармеецларына, курсантларына, командирларына, шулай ук «Сугышчан дус» исемле самолетлар эскадрильяләре төзүгә 790.000 сум акча керткән фронтовиклар хатыннарына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

КАЗАХСТАН ССР, КАРАГАНДА ӨЛКӘСЕ, НУРИНСКИЙ РАЙОНЫ, МАРЖАНСКУЛЬ СОВХОЗЫ ЭШЧЕ КОНСТАНТИН ГРИГОРЬЕВИЧ СВИСТУНОВ ИПТӘШКӘ

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгырткан өчен рәхмәт Сезгә, Константин Григорьевич.

Сәламемне кабул итегез

И. СТАЛИН.

КӨНЬЯК КАЗАХСТАН ӨЛКӘСЕ, ПАХТА-АРАЛ РАЙОНЫ, АНДРЕЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ КОЛХОЗ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ БАЙМЕНДЕЕВКА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгыртуыгыз өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез, иптәш Баймендеев.

И. СТАЛИН.

АЗЕРБАЙҖАН ССР, ПУШКИН РАЙОНЫ, МОЛОТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ КОЛХОЗ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ АЛИ ДАДАШ УГЛЫ КОРБАНОВ ИПТӘШКӘ

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгырткан өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез, иптәш Корбанов.

И. СТАЛИН.

ГРУЗИЯ ССР, ТИАНЕТЫ РАЙОНЫ, МАХАРАДЗЕ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ КОЛХОЗ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИЛЬЯ ДАВЫДОВИЧ ЧЕНЧАРАУЛИ ИПТӘШКӘ

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгырткан өчен Сезгә һәм Махарадзе исемендәге колхозның колхозчыларына рәхмәт әйтәм.

Минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез.

И. СТАЛИН.

САРАТОВ ӨЛКӘСЕ, РОДНИЧЕК РАЙОНЫ, ИЛЬИЧ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АРТЕЛЕ КОЛХОЗЧЫ ЯКОВ ВАСИЛЬЕВИЧ ИСАЕВ ИПТӘШКӘ

Кызыл Армиянең һава көчләре турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез, Яков Васильевич һәм Мария Никаноровна.

И. СТАЛИН.

ИРКУТСК ӨЛКӘСЕ, ИРКУТСК АВЫЛ РАЙОНЫ КОТИНСК АВЫЛ СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ А. И. ОСТАПЕНКОГА

Кызыл Армия турында кайгыртуыгыз өчен рәхмәт Сезгә, Анна Ивановна.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

САРАТОВ ӨЛКӘСЕ, САЛТЫКОВ РАЙОНЫ, ИЗНАИР АВЫЛЫ УКЫТУЧЫ ВСЕВОЛОД ПАВЛОВИЧ ЮРЬЕВ ИПТӘШКӘ

Кызл Армиянең һава көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен рәхмәт Сезгә, Всеволод Павлович.

Сәламемне кабул итегез

И. СТАЛИН.

ЧИТА ӨЛКӘСЕ, БУРЯТ-МОНГОЛЛАРНЫҢ АГИНСК МИЛЛИ ОКРУГЫ, ДУЛЬДУРГИН РАЙОНЫ, «ОНОН» КОЛХОЗЫ КОЛХОЗ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ ЭЛЬДЫПОВКА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгырткан өчен «Онон» колхозы колхозчыларына һәм Сезнең үзегезгә, иптәш Эльдыпов, рәхмәт.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

МӘЛӘКӘС. КУЙБЫШЕВ ӨЛКӘСЕ АНАСТАСИЯ ДМИТРИЕВНА АРТАМОНОВАГА

Кызыл Армиянең һава көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен Сезгә рәхмәт, Анастасия Дмитриевна.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

ЧКАЛОВ ӨЛКӘСЕ, ТАШЛЫ РАЙОНЫ, 16 НЧЫ ПАРТСЪЕЗД ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ ДМИТРИЙ ИВАНОВИЧ ПЫШКИНГА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгыртуыгыз өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез, Дмитрий Иванович. Сезнең теләгегез үтәлер.

И. СТАЛИН.

КАЛЯЗИН. КАЛИНИН ӨЛКӘСЕ ВКП(б) НЫҢ КАЛЯЗИН РАЙКОМЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ КЕРБУНОВКА

Калязин районының «Калинин фронты» исемле танклар колоннасы төзелешенә 3.247.000 сум акча җыйган колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.



Н-че заводларның берсендә эшләнеп чыккан танклар. ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

15 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

15 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның түбәнге агымы районында, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары немецларны ныгытмалардан һәм йортлардан бәреп чыгардылар. Н-че часть сугышчылары дошманның 56 ДЗОТ ын җимерделәр һәм бер урамны дошманнан чистарттылар. 5 орудие, 4 миномет, 20 пулемет, 150 винтовка һәм сугыш припаслары кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аның контратакаларын кире кайтарып, һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта дошман танкларының һәм пехотасының зур көчләре контратака ясаганнар иде. Совет гаскәрләре гитлерчыларның басымын тоткарладылар, ә соңыннан аларны элекке позицияләренә алып ташладылар. 800 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 19 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр дошманны халык яши торган, көчле рәвештә ныгытылган бер пункттан бәреп чыгардылар һәм бер бронемашина, 4 орудие, 6 миномет, бер сугыш припаслары склады һәм бер радиостанция кулга төшерделәр.

* * *

Үзәк фронтта Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак немецларның 2 батальон пехотасы һәм автоматчиклар отряды, танклар һәм бронемашиналар ярдәме белән, Н-че часть позицияләренә атака ясадылар. Бик каты сугыш нәтиҗәсендә гитлерчылар элекке позицияләренә алып ташландылар. Сугыш кырында дошманның 200 дән артык үле гәүдәләре һәм сафтан чыгарылган 8 танкысы калды. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошманның берничә терәк пунктын алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм 250 пленный алынды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Немецлар, совет частьларының алга баруларын тоткарларга маташып, берничә контратака ясадылар. Контратакалар барысы да дошман өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. Н-че часть участогында бер төн эчендә немецларның бер ротадан артык пехотасы юк ителде, 4 танкысы һәм 7 автомашинасы зарарланды һәм яндырылды. Безнең артиллерия уты белән дошманның 2 сугыш припаслары склады шартлатылды.

* * *

Курск өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары январь башында дошман кулындагы бер тимер юл станциясенә һөҗүм ясаганнар һәм 95 гитлерчыны кырып ташлаганнар. Совет патриотлары станциянең җиһазларын, телефон-телеграф узелын, күмер төялгән 18 вагонны һәм бер сугыш припаслары складын шартлатканнар. Партизаннар 600 метр озынлыкта ике линияле тимер юлны җимергәннәр. Бу участокта поездлар хәрәкәте берничә тәүлеккә туктатылган.

Ростов өлкәсенең немецлар оккупацияләгән бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманга каршы сугышларда 40 тан артык гитлерчыны кырып ташлаган. Партизаннар 5 пулемет, 100 дән артык винтовка һәм күп сугыш припаслары кулга төшергәннәр.

* * *

Ростов өлкәсенең хәзер азат ителгән Заветное авылында торучылар немец-фашист кабахәтләрнең коточкыч җинаятьләре турында сөйләделәр. Сентябрь ахырында авылга эсэсчы башкисәрләр отряды килеп чыккан. Гитлерчылар башка өлкәләрдән күчерелгән совет гражданнарын, шулай ук колхоз активистларын һәм аларның семья членнарын көнө-төне аулап йөргәннәр. **Бандитлар тоташ семьяларны автомашиналарга төяп авыл читенә алып чыкканнар һәм шунда бик озак мыскыллап, җәзалагannан соң үтергәннәр. Немецлар бу газаплап үтерелгән кешеләрнең үле гәүдәләрен җыеп алуны һәм күмүне тыйганнар. Беренче алынган саннарга караганда, гитлерчылар 300 гә якын совет гражданнарын үтергәннәр.**

15 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

15 нче январьда безнең гаскәрләр **Төньяк Кавказда**, һөҗүмне дәвам иттереп, **Благодарное** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Александровское** шәһәрен, район үзәге **Солуно-Дмитриевскоены**, халык яши торган зур пунктлардан **Садовоены, Нагутскоены, Бекешевскаяны** һәм тимер юл станциясе **Нагутскаяны** алдылар.

Төньяк Донец районында безнең гаскәрләр район үзәге **Литвиновканы**, халык яши торган зур пунктлардан **Груциновны, Самбурсвны, Дядинны, Поцелуевны, Бородиновны, Ерофеевканы** һәм тимер юл станциясе **Глубокаяны** алдылар.

Зимовники районында безнең гаскәрләр район үзәге **Орловскаяны**, халык яши торган зур пунктлардан **Батлаевскаяны, Московскийны, Татниковны, Рясканы, Денисовскийны, Новая Надежданы, Атамановскийны, Грековны, Красное Знамяны, Луганскийны, Быстрянскийны, Потемкинскийны, Кундрюченскийны** һәм тимер юл станцияләре **Двойнаяны** һәм **Куренныйны** алдылар.

* * *

14 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 60 автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 7 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер тимер юл составын җимерделәр, 3 сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар, ике ротага якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында **безнең штурм отрядлары, дошманның контратакаларын кире кайтарып, 600 метр алга киттеләр. Тагын берничә урам гитлерчылардан чистартылды. 600 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары, дошманның 100 дән атык ут точкасын һәм блиндажлары юк ителде, берничә танкысы сафтан чыгарылды.**

Безнең очучылар аэродромнарда дошманның 7 самолетын юк иттеләр һәм һава сугышларында 3 самолетны бәреп төшерделәр.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары бер көн эчендә халык яши торган берничә пунктны немец-фашист басып алучылардан азат иттеләр. Дошманга каршы бик каты сугышларда 400 дән артык гитлерчы юк ителде, пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта немецлар шуннан элек югалткан уңайлы бер позицияне кайтарып алырга маташып карадылар. Дошманның барлык контратакалары аның өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды.

* * *

Үзәк фронтта, Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак һәм төньяк-көнбатыштарак, безнең гаскәрләр дошманның контратакаларын кире кайтардылар һәм аны зур югалтуларга дучар иттеләр. 500 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды. Командиры иптәш Простяков булган часть соңгы сугышларда немецларның бер батальон пехотасын кырды һәм 9 танкысын юк итте. Икенче бер участокта кече лейтенант Гордиенко командалыгындагы подразделениенең сугышчылары халык яши торган 2 зур пункт арасындагы шоссе юлын саклап торалар иде. Немец автоматчикларының бер отряды, 10 танк ярдәме белән, бу юлны алырга маташып карады. Безнең сугышчылар дошманның 2 танкысын һәм берничә дистә солдатын юк иттеләр. Икенче көнне гитлерчылар атаканы тагын кабатладылар, ләкин, 4 танкларын һәм шактый күп солдатларын югалтып, чигенергә мәҗбүр булдылар. Дошман танкларының 6 сын да танкка каршы атторган мылтыктан атып сержант иптәш Никитин яндырды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Безнең хәрәкәттәге отрядларыбыз дошманның тирән тылларына үтеп чыгалар һәм аларның коммуникацияләрен җимерәләр. Н-че берләшмә частьлары, сугыша-сугыша алга барып, халык яши торган берничә пунктны һәм бер тимер юл станциясен алдылар. Гитлерчыларның бер участокта совет гаскәрләренең алга баруларын тоткарларга маташулары барысы да дошманның тар-мар ителүе белән тәмам булды. 1.500 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары, дошманның 7 танкысы, 10 орудиесе һәм 12 бронетранспортеры юк ителде. 5 сугыш припаслары склады шартлатылды. Безнең частьлар 36 танк, 1.200 автомашина, шуның өстенә автомашиналар төялгән 3 тимер юл эшелоны, киемнәр һәм азыклар төялгән 5 эшелон, терлек төялгән бер эшелон, 10 парсвоз, 200 вагон һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер учсатокта безнең алгы частьларыбыз халык яши торган бер зур пунктка барып чыктылар һәм дошман гарнизонына каршы сугыш башладылар. Немецларның 13

(Ахыры 4 нче биттә).



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Сталинградтан төньяк - көнбатыштарак). Сaперлар юлны миналардан чистарталар. Рәсемдә: ТАСС фотохроникасы.

„СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ“

Фронттан меңнәрчә километрда, тирән тылда урнашкан завод. Биредә туплар үкерүе дә, пулялар, миналар сызгыруы да, снарядлар, бомбалар шартлавы да ишетелми.

Ләкин, колак белән ишетелмәгән, күз белән күренмәгән нәрсәләрне тоя торган нәрсә—йөрәк бар. Ерак тылдагы заводның коллективы үзенең бөтен йөрәге белән сәгать саен, минут саен фронтны тоя, аның белән бергә сулый, аның вакытлы уңышсызлыклары өчен сызлана, җиңүләре өчен шатлана.

...Смена башланырга әле ярты сәгать бар. Фуговальный станок тирәсен эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар сырып алганнар, ә станок янында—мастер Елиф. Ул әле генә өендә радио аша тыңлап килгән Совинформбюро хәбәрләрен башкаларга сөйли.

— Безнең гаскәрләр Үзәк фронтта, Донның урта агымында, Сталинградтан көньякта һәм көньяк-көнбатышта, Төньяк Кавказда уңышлы рәвештә һөҗүм сугышлары алып баралар...

Елиф, азат ителгән шәһәрләрнең, авылларның һәм тимер юл станцияләренең исемнәрен, юк ителгән дошман техникасының, кырып ташланган фашистларның санын, һөҗүм итеп үтелгән юлның озынлыгын—барысын да язып алган, шуларны иптәшләре белән уртаклаша. Ул бетерүгә башкалар сөйли башлый, үзләренең тәэсирләре турында һәркем үзенең фикерен әйтеп калырга ашыга, һәрбер чыгышның ахыры шуңа кайтып кала.

— Алар анда, без монда, шулай бергәләп тотынсак, немец озакка чыдамас!

— 1914—18 нче елгы сугыш ветераны Иван Данилович Баташев өстәп куя:

— Теге вакытта да пешергән идек без аны, хәзер бигрәк тә. Патша вакыты дип белмәсен ул хәзер!

Шулай итеп стихияле рәвештә митинг башланып китә һәм бу көн саен, һәрбер цехта кабатлана. Кешеләрнең йөзләрен әйтеп бетергесез шатлык балкыта. Һәркемдә үзенең сөекле Кызыл Армиясе өчен; аның сафларында сугышучы туганнары, ирләре, уллары, әтиләре өчен чиксез горурлык уяна һәм эшкә булган дәрт, хезмәт энтузиазмы бермә-бер арта.

— Ишеттегезме әле, кордаш,—ди Салах абзый Сәйфетдинов үзенең күршесе Иван Яковлевич Ефимовка эндәшеп,—безнекеләр Великие Луки шәһәрен алганнар бит!

— Синнән алданрак ишеттем инде. Минем өйдә радио бар бит, пожалуй, минем малай да катнашкандыр әле, шул тирәдәнрәк язган иде,—һәм бераздан ул күршесеннән сорап куя:

— Ә синеке кайдан яза?

— Кайдан икәнен әйтеп бетерми, полевая почта номеры гына бар.

— Барыбер анда да безнекеләр алдыра инде, озакламый, пожалуй, капут немецка!

— Шулай булсын инде, кордаш!

Бераз сүзсез эшлиләр, аннан бер-береннән сорашып куялар:

— Ничә булды әле күрше?

— 37 әзер, бүген 220 гә куарга исәп бар...

— Ә мин 230 дан да ким бирмим бүген.

— Ярыласың бераз.

— Менә күрерсең!

Һәм алар арасында кәгазьгә язылмаган кызу ярыш башлана. Нәтиҗәдә, ул көнне алар икесе дә норма буенча 43 урынына 235 әр деталь эшлиләр. Бу аларның фронттагы улларының героик эшләренә биргән җаваплары.

Сәйфетдинов һәм Ефимов — алар заводның карт столярлары, һәркайсысының уллары фронтта, үзләре биредә тырышалар, сменага икешәр, өчәр норма бирәләр. Кирәк вакытта 16 шар, 18 әр сәгать эшлиләр. «Без картайган инде» дип тормыйлар, киресенчә, соңгы вакытларда фронт ягыннан килә торган шатлыклы хәбәрләр аларны бераз яшәртеп җибәрде шикелле. Бер алар белән генә түгел, заводтагы йөзләрчә башка эшчеләр белән дә шундый хәл. Һәркем фронтка ярдәмне көчәйтергә, дошманга үлем китерә торган продукция эшләп чыгаруны арттырырга омтыла.

Совет Информбюросының иртәнге белдерүен тыңлап, рухланып килгән кеше кичен зур шатлык белән үзенә шундый отчетны бирә:

— Мин бүген фронт заказы өчен 45 полуфабрикат бирдем, ә иртәгә 50 булыр!

Менә украиналы Аделия Осиповна Закревская. Аңар инде 40 яшь. Физик яктан тазалыгы да ул кадәр мактанырлык түгел. Шулай да, бер операцияне үтәр өчен ирләр җитмәгәч, алар урынына басу аны куркытмады. Чөнки вакыты шундый. Уннарча башка хатын-кызлар белән бергә ул, гаять катлаулы һәм авыр булган бу операцияне рекордлы срок эчендә үзләштерде һәм нормасын 2 шәр мәртәбә арттырып үти башлады. Декабрь аенда ул айлык планын 199 процентка үтәде.

Сугышка кадәр иптәш Закревская Белоруссиянең трикотаж фабрикаларыннан берсендә эшли иде. Хыянәтчел рәвештә һөҗүм итеп, советлар җиренә басып кергән немец бандитлары аны үзенең туган илен ташлап китәргә мәҗбүр иттеләр. Менә ел ярым инде ул яңа җирдә, яңа шартларда эшли. Шушы ел ярым вакыт эчендә ул үзен намуслы, хезмәт сөяр, тырыш бер эшче һәм ялкынлы патриотка итеп танытты. Нинди генә эштә булмасын, сугышчан заданиене һәрвакыт арттырып үтәде.

Хәзер Кызыл Армия частьлары аның туган шәһәренә якынаеп баралар. Шунлыктан ул фронт хәбәрләрен йотлыгып көтеп ала.

— Нәрсә тапшырдылар бүген соңгы сәгатьтә?—дип сорый ул һәркөн ир-

(АХЫРЫ 3 нче БИТТӘ).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫН ЯҢА ҖИҢҮЛӘР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК!



«Трикотаж» артелендә. Рәсемдә: ремонт цехы җитәкчесе иптәш Җиһаншина яшь эшче Шурыгинаны трикотаж әйберләргә ремонт ясарга өйрәтә.
С. Парфенов фотосы.

ЯШЬ ТОКАРЬ ӘХМӘТНЕҢ ВЗНОСЫ

езмәт резервлары" исемле танклар колоннасы һәм авиаэскадрилья төзелешенә средство туплау республикабызның барлык һөнәр училищеларында да зур күтәренкелек белән бара.

Менә 3 нче номерлы һөнәр училищесы. Аның укучылары үзләренең саклык акчаларын сугыш машиналары төзүгә бирделәр. Училищеның иң яхшы укучысы Әхмәт Әхтәмов бер ел эчендә токарьлык профессиясенә өйрәнде. Хәзер ул хәрби заказларны үтәүдә норманы 180—250 процентка үтәп бара.

Аның әтисе фронтта. „Хезмәт резервлары" исемле авиаэскадрилья төзү фондына средство туплау башлангач та Әхмәт Әхтәмов 1 500 сум акча кертте:

— Минем әтием фронтта. Мин аңа яхшы сыйфатлы кораллар эшләп чыгару өчен хезмәтемне кызганмыйм. Дәһшәтле сугыш коралларын төзүгә кирәкле средствоның бер өлешен каплау өчен үземнең саклык акчамны да бирәм,—диде.

А. ФИЛИМОНОВА.



Рәсемдә: Заготзерноның Казан пункты лаборанткасы иптәш Макаловская пунктка китерелгән ашлыкның сыйфатын тикшерә.
К. Тахтеев фотосы.

ДОШМАННЫ ТИЗРӘК ҖИҢҮ ӨЧЕН

ЧИСТАЙ, 15 январь. (**Телефон буенча**). «Красная звезда» такта заводы коллективы фронт өчен, явыз дошманны тизрәк тар-мар итү өчен армый-талмый эшләп, зур уңышларга иреште. Бу завод коллективы такта яру һәм агач эшкәртү предприятиеләре буенча Бөтенсоюз социалистик ярышында узган айда икенче урынны яулап алуга ирешкән иде. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр, Кызыл Армиянең 25 еллыгын зур уңышлар белән каршылау өчен ярышка кушылып, январь ае планын 150 процентка үтәргә йөкләмә алдылар.

Лесзаг коллективы еллык планны срогыннан элек үтәү өчен ярышка чыккан иде. Алар сүзләрендә нык тордылар: еллык планны Октябрь бәйрәменең 25 еллыгына ук төгәлләделәр. Коллектив хәзер Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган социалистик ярышка бердәм рәвештә кушылып, беренче квартал планын ике айда үтәргә йөкләмә алды.

Ворошилов исемендәге артель декабрь ае планын 140 процентка үтәп чыкты һәм 5.000 сум акча белән бүләкләнде. Артель коллективы Кызыл Армиянең бөек еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршы алу өчен көрәшә.

Ш. ШАКИРОВ.

ЭНЕРГЕТИКЛАР ЙӨКЛӘМӘСЕ

Партоешма секретаре урынбасары иптәш Ставер булган Н-че заводның энергетиклары, Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган социалистик ярышка актив рәвештә кушылып, үз эшләренә яңа, конкрет йөкләмәләр алдылар.

—Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә заводның ике айлык программаны тулысынча үтәве өчен кирәк булган барлык төр энергия белән цехларны тоткарсыз тәэмин итеп торырга.

—Электр энергиясенә алда тагын да экономия чараларын үткәреп, 23 нче февральгә кадәр булган вакыт эчендә цехларда электр энергиясе тотуны, нормага караганда, 8 процентка киметүгә ирешергә. Казан цехында ягулык тотуны, декабрь белән чагыштырганда, 5 процентка киметергә.

Завод энергетиклары бөек датаны —Кызыл Армиянең 25 еллыгын лаеклы рәвештә каршылауда әнә шушыларга ирешү өчен көрәшәләр. Үткәрелгән митингта, шулай ук, үзләренең барлык саклык акчаларын Советлар Союзы Герое Марина Раскова исемендәге самолетлар эскадрильясе төзү фондына кертү турында бер тавыштан карар кабул ителде. Митинг барышында ук 16 мең сум акча җыелды. Эскадрильялар өчен средстволар җыю дәвам итә.

Темплар үсә

Микоян исемендәге кондитер фабрикасы коллективы Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә социалистик ярышка кушылып алган йөкләмәләрен намус белән үтәү өчен үзенең барлык көчен бирен эшли. Соңгы көннәрдә эш темплары аеруча яхшы. Фабриканың барлык цехлары да үз планнарын арттырып үтиләр. Венский цех аеруча югары күрсәткечләр бирә. Анда 13 нче январьда план 184,6 процентка, 14 нче январьда—176,9 процентка үтәлде. Соңгы көннәрдә фабрика күләмендә план 127—133 процентка җиткереп үтәлә.

Ярыш барышында фабрикада стахановчыларның саны арта. Шеколад цехыннан Крыгин, Пашкова, Сөләйманова, Аграновская һ. б. иптәшләр нормаларны 200-300 процентка, Ильин, Авдеев, Соловьева, Фомин (венский цех), Нәҗипова, Пальжева, Гарипова, Шәкурова; Феклина (пряник цехы)—150—200 процентка үтиләр.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

ПУЧЫ, 15 январь. (**Телефон буенча**). «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү фондына Калинин районы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары 1 миллион 300 мең сум акча тупладылар. Бу эш дәвам итә. Шулай ук колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запаслардан Кызыл Армия фондына ашлык та тапшырдылар. «Таш елга» колхозы членнары—500 пот, Ворошилов исемендәге колхоз членнары—400 пот, «Коминтерн» колхозы членнары—750 пот һәм Воровский исемендәге колхоз членнары—730 пот ашлык тапшырдылар.

Район буенча бу фондка барлыгы 3.500 пот ашлык җыелды.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ УҢЫШЛЫ ҺӨҖҮМЕНӘ ҖАВАП ИТЕП

Безнең данлыклы Кызыл Армиябез Ватан сугышының барлык фронтларында фашистик бандаларга каршы уңышлы һөҗүм алып баруны дәвам итә. Бу турыдагы көндәлек хәбәрләр мине гаять рухландыралар. Мин Кызыл Армиябезнең уңышлы һөҗүменә җавап итеп, сугышчан самолетлар эскадрильясе төзү фондына үземнең саклык средстволарымнан 3.000 сум акча кертергә карар бирдем. Минем катнашым белән төзелгән самолет фашистик кабахәтләрнең башларына үлем яудырсын.

Г. ГЫЙСМӘТУЛЛИН,
Казгорпищеторг хезмәткәре.

Графнк төгәл үтәлә башлады

КУКМАРА, 15 январь. (**Телефон буенча**). Кукмара МТС ы быел барлыгы 56 тракторга ремонт ясарга тиеш. Шуларның 25 е ремонттан чыкты инде. Дөрес, 4 нче квартал планы үтәлеп җитмәгән иде. Соңгы көннәрдә, Кызыл Армиябезнең фронтлардагы уңышлары белән рухланып, ремонтта эшләүче эшчеләр графикны төгәл үтәп баруга җитди игътибар бирә башладылар. Ремонтта эшләүчеләрнең барысы да дип әйтерлек узара ярышып эшлиләр. Ярыш бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Газизуллин һәм Савельев иптәшләр кебек күнлек нормаларны 200 процентка үтәп баручы стахановчылар саны бу МТС та шактый күбәйде. Нәтиҗәдә, январьның өченче биш көнендә ремонт графигы төгәл үтәлде: шул бишькөнлектә ремонттан 4 трактор чыгарга тиеш иде һәм чыкты.

Эшчеләр тракторларга ремонт ясауны героик Кызыл Армиябезнең 25 еллыгына кадәр (20 нче февральгә) тәгәлләүне йөкләмә итеп алдылар.

Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау да соңгы көннәрдә уңышлы гына бара башлады. 65 сабанның 22 се, 35 чәчү машинасының 20 се ремонтланды инде. Ремонтның сыйфаты яхшы. Ремонттан чыккан һәрбер машина акт буенча кабул итеп алына.

Иске детальләрне яңартуга нык әһәмият бирелә. 44 нче, 448, 447 һәм башка детальләргә реставрация ясау аеруча уңышлы бара. МТС запас частьларга реставрация ясау буенча 4 нче квартал планын үтәде.

„СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ"

(АХЫРЫ, БАШЫ 2 нче БИТТӘ).

тән,—әмма кыен да инде шушы үз өендә радио юклыгы! Кешеләр нәрсәнедер әйтеп бетермәсләр шикелле...

Ләкин, кешеләр аңа барысын да әйтәләр. Әле күптән түгел генә аңар, гомуми шатлыклы хәбәрләр белән берлектә, аның өчен генә хас булган тагын бер шатлыклы хәбәр—туганына генерал-майор исеме бирү турында белдерделәр. Аның шатлыгы эченә сыймый.

— Әле күптән түгел генә үзен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләгәннәр иде, менә хәзер тагын... Котлау телеграммасы җибәрергә кирәк әле үзенә...

Фронт белән завод арасын меңнәрчә километрлар аера. Бирегә туп тавышлары да, пуляләр сызгырган, бомбалар шартлаган тавышлар да килеп җитмиләр. Ләкин йөгерек радио дулкыннары фронтның һәрбер сулышын, һәрбер талкыр тибүен минутында ук китереп җиткерә. Фронттагы геройлыкларга тылдагы геройлыклар җавап бирә. Фронттагы һөҗүмгә җавап итеп хезмәт фронтында да һөҗүм көчәйтелә.

Үткән елның декабрь ае завод коллективы өчен кызу эш ае булды. Коллектив алдына сугышчан бурыч куелган иде. Бу бурыч кыскача «6.200» цифры белән аңлатылды. Цехлар, участоклар, сменалар, бригадалар һәм аерым стахановчылар һөҗүмгә ташландылар. Кул астында булган барлык ресурслар мобилизацияләнде. Ирләр җитешмәгән участокларга хатын-кызлар килде. Инструментлар җитешми иде—Хатанов, Ракин, Морозов иптәшләр өйләреннән үз инструментларын китереп бирделәр. 12 кешелек столярлар группасы үзен мобилизовать ителгән дип игълан итте һәм 16 сәгатьлек эш көненә күчте. Контора хезмәткәрләре, үзләренең эш көннәре беткәннән соң, 4 әр сәгать производствога барып эшләделәр. Заказның төп операцияләре үтәлә торган китеп. Морозов цехында аеруча кызу булды. Нәтиҗәдә бу цех декабрь ахрына «6.200» урынына «7.017» дип рапорт бирде—һәм заказның бөтен завод буенча үтәлүен тәэмин итте.

Бу—фронттан «Соңгы сәгатьтә» килә торган җиңү хәбәрләренә җавап булган бик гүзәл җиңү иде.

Январь аенда да һөҗүм үзенең бөтен көче белән дәвам итә. Күптән түгел генә цехларда яңа митинглар булып үтте. Көн тәртибе—радио китергән шатлыклы хәбәрләр, безнең гаскәрләрнең һөҗүменең алты айлык йомгаклары турында информация иде. Карар бик кыска булды. Завод коллективы үз өстенә яңа йөкләмәләр алды:

— Хезмәт фронтындагы һөҗүмне көчәйтергә, январь планын бөтен күрсәткечләр буенча арттырып үтәргә, үзенә төшү бәясен, чимал, электроэнергия тотуны ... процентка киметергә, махсус фронт заказын вакытыннан алда үтәргә һ. б.

Шулар өстенә, завод коллективы Кызыл Армиянең данлыклы 25 еллыгы хөрмәтенә фронтовикларга 45.000 сумлык бәйрәм бүләкләре алып җибәрергә карар бирде.

Гомуми договор нигезендә, цехларда; сменаларда, бригадаларда, аерым эшчеләр арасында социалистик ярыш договорлары төзелде. Ярыш киң колач белән җәелеп бара. Сергеев, Убогий, Сәйф...ов һәм Ефимов иптәшләр нормаларын 200 процентган да ким үтәмәскә ... алдылар һәм алар бу йөкләмәләрен намус белән үтәп баралар.

* * *

Бу мәкаләнең ахырында завком председателе иптәш Федоров адресына берничә сүз әйтеп үтәсе килә.

Халык фронт хәбәрләре белән чиктән тыш кызыксына, газеталар аша бу хәбәрләр кичегеп киләләр, иң якын хәбәрләшү чарасы булган радио һәркемнең дә өендә юк әле. Цехларда ул бөтенләй юк. Шунлыктан завод комитеты цехларда, ашханә, магазин шикелле җәмәгать урыннарында радио точкаларын булдыру чарасын күрсен иде.

И. ФӘЙЗУЛЛИН,
3 нче фанера заводы, Зеленодольск шәһәре.

Совет Информбюросыннан

15 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

* * *

танкысы кулга төшерелде һәм 400 дән артык кеше плен алынды.

Белоруссия партизаннарының Могилев өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отряды сугышта 96 немец солдатын һәм офицерын кырып ташлаган. Күп гитлерчылар яраланган. Сугыш кырында дошманның зарарланган бер бронемашинасы һәм сафтан чыгарылган бер танкеткасы калган. Гомель партизаннарының бер отряды кинәт немецлар гарнизонына һөҗүм итеп, 40 немецны үтергән. 3 пулемет, 30 винтовка, 8 револьвер һәм сугыш припаслары кулга төшерелгән.

* * *

Немецларның 6 нчы танк дивизиясенең 114 нче моторлаштырылган гренадер укчы полкыннан бер группа солдатлар Кызыл Армия ягына чыктылар. Плен алынган Альфред М., Генрих Б., Вильһельм К. һәм башкалар болай диделәр: «Соңгы вакытларда безнең дивизия Франциядә булды. Анда полклар оештырылдылар һәм бик нык өйрәнүдән үттеләр. Дивизия Көньяк Франциянең моннан элек оккупацияләнмәгән районнарын алып шунда урнашыр дип уйлаганнар иде. Ләкин көтмәгәндә бөтенесе үзгәреп китте. Ноябрь ахырында безне ашыгыч рәвештә Россиягә җибәрделәр. Без үзебезне фронтның кайсы участогына җибәрүләрен белмәдек, ләкин һәркемнең рухы төшенке иде. Фронтта дивизия алдына башка берләшмәләр белән бергәләп Сталинград янына барып чыгарга һәм анда чолганып калган гаскәрләрне коткарырга дигән бурыч куелды. Командование приказы буенча без рождествоның беренче көнендә Сталинградта булырга тиеш идек. Берничә көн сугышкач безнең дивизия 60 танкысын һәм гаять күп кешесен югалтты. Безнең алда ике генә юл калды—я һәлак булырга, яки сугыштан чыгарга. Без үзара килешеп, пленга бирелдек».

(Радио буенча алынды).

—☆—

ШЫРПЫ ПРОИЗВОДСТВОСЫ

Зеленодольскидагы 3 нче фанера заводы янында узган елның август аеннан бирле шырпы цехы эшли. Узган елның 5 ае эчендә 750.000 книжка шырпы эшләнде. Хәзер бу цех, күбесенчә производство калдыкларыннан, ай саен 200.000 книжка чамасы шырпы эшләп чыгара.

Биредә эшләүчеләрнең барысы да диярлек яшь үсмер балалар, аларның күбесе балалар йортларыннан килгәннәр.

Бу нәни эшчеләр арасында стахановчы исемен яулап алган гаять тырыш үсмерләр бар. Мәсәлән, Балясов, Морозов иптәшләр циркуль станогын гаять яхшы үзләштерделәр. Алар көн саен нормаларын 175-200 процентка кадәр җиткереп үтиләр. Шулай ук фрезеровщица Баташева һәм Галкина иптәшләр дә икейөзпроцентчылар исемен нык саклыйлар.

И. Ф.

—○—

ГАЗЕТАГА БАСЫЛМАГАН ХАТЛАР ЭЗЕННӘН

Кукмара районы, «8 нче март» колхозы председателе Мулюковның үз эшенә салкын карап, колхозда эшне таркатуга таба алып баруы турындагы хәбәр район советы башкарма комитеты тарафыннан тикшерелде. Фактлар расландылар. Колхозчыларның 1 нче январьда булган гомуми җыелышы Мулюковны колхоз председательлегеннән алды. Мулюковның җинаятьләре турындагы материал район прокурорына бирелде.

* * *

Кайбыч районы, Шыгай авыл советына караган «Татарстан» колхозы членнары Г. Мифтахова һәм А. Гыйлаҗовларның колхоз милкен урлау белән шөгыльләнүләре турындагы хәбәр район прокуроры тарафыннан тикшертелде һәм хәбәрдә күрсәтелгән фактлар расландылар. Район суды Мифтахованы ике елга иреккәннән мәхрүм итәргә хөкем итте, Гыйлаҗовка кисәтү ясалды.



ТӨНЬЯК АФРИКА. Рәсемдә: Африка тарафыннан алып барыла торган хәрби пунктларыннан берсендә америкалылар тәзелеш өчен дөяләрдә кирпеч күчерү.

ТАСС фотохроникасы.

ГЕРМАНИЯНЕҢ ЯЛГАН ПРОПАГАНДАСЫ ТУРЫНДА АМЕРИКА МАТБУГАТЫ

НЬЮ ЙОРК, 14 январь. (ТАСС). «Нью-Йорк» теральд трибюн» газетасы совет гаскәрләренең һөҗүме башланганнан соң Гитлер пропагандасының яңадан хурлыклы тестә җимерелгәнлеге турында мәкалә басып чыгарган. Мәкаләдә болай диелә: «Руслар һөҗүм башлаганнан соң Гитлерның эчке пропагандасы һәм чит илләр өчен булган пропагандасы, буталып бетеп, бер позициядән икенчесенә сикерә башлады. Башта ул русларның белдерүләре турында бер сүз дә әйтмәде, соңыннан алардан көләргә, ә аннан соң аларны инкар итәргә маташты. Декабрь уртасыннан башлап Германия пропагандасы, фантастик каршылыкларга кереп чуалып бетеп, башка тактика алырга, ягъни Советлар Союзы белән сугыш турында бер сүз дә дәшмәскә маташып карады».

Газета Германиянең верховный командованиесенең Геббельс трюкларына иярүен күрсәтеп үтә. Газета болай ди:

«Германия верховный командованиесе сугыш хәрәкәтләренең барышы турында үзе өчен хәлләр уңайлы була башлагач кына хәбәр итә ала күрәсең. Үткән елны әле ул Кызыл Армиянең кайбер шәһәрләрне алуын икърар иткән иде Быел кыш ул бер нәрсәне дә икърар итми. Күптән түгел Германия командованиесе пропаганда максаты белән, сугыш хәрәкәтләренең барышы турында ялган хәбәрләр игълан итте. Мәсәлән, 4 нче январьда Германия белдерүендә: «Бомбардировщиклар, берничә дулкын булып, Англиядәге Гулль шәһәренә һөҗүм ясадылар,—диелгән иде. Америка хәбәрчеләренең әйтүенчә исә бу «дулкыннар» ике бомбардировщиктан торган. Германия генераллары Геббельс хыялының нәтиҗәсе булган шундый акыятләр уйлап табарлык хәлгә төшкәч инде аларның эшләре бик начар булса кирәк».

СОЮЗНИКЛАР АВИАЦИЯСЕНЕҢ ЛИЛЛЬГӘ ҺӘМ АБВИЛЬГӘ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 14 январь. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә көндез Англия һәм Америка самолетлары, доминионнар һәм союздаш илләр авиациясе бергәләшеп Төньяк Франция өстенә зур операция үткәргәннәр. «Оча торган крепостьлар», зур биеклектән, Лилльдә Германия өчен сугыш продукциясе җитештерүче промышленность предприятиеләрен бомбага тотканнар. Күп урыннарда янгыннар һәм шартлаулар күренгән.

Англиянең «Бостон» бомбардировщиклары дошманның Абвильдәге аэродромына һөҗүм иткәннәр.

Бу операцияләргә 400 ләп истребитель булышлык иткән.

13 нче январьда иртә белән Англиянең истребитель авиациясе Голландиядәге каналларда дошман баржаларына, шулай ук артиллерия позицияләренә атака ясаган. «Москито» бомбардировщиклары Төньяк Франциядәге күп кенә тимер юл үзәкләренә һөҗүм иткәннәр. Һөҗүм ясалган районнарның барысында да зур янгыннар һәм көчле шартлаулар булган.

Дошман авиациясе гадәттән тыш аз каршылык күрсәткән.

ЮГОСЛАВИЯДӘ ПАРТИЗАНЛЫК КӨРӘШЕ

ЖЕНЕВА, 14 январь. (ТАСС). Югославия партизаннары, оккупантларның һәм усташиларның гаскәрләрен уңышлы рәвештә тар-мар итүне дәвам иттереп, Томислав-Град районында дошманның көчле атакасын кире кайтарганнар. Дошман, күп кешеләре үтерелеп, күп коралларын югалтканнан соң, элекке позицияләренә чигенгән.

Сунья шәһәре районында партизаннар каты сугышлардан соң Майяр станциясенә ныгып урнашканнар. Бу станция берничә тапкыр кулдан-кулга күчкән булган.

Плашки—Карловац тимер юл участогында бер группа партизаннар дошманның хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Күп кешеләр үлгән. Исән калган бер офицер һәм 20 солдат пленга бирелгән. Партизаннарның икенче бер группасы Скрад тимер юл станциясен җимергән. Шул чакта пленныйлар алынган һәм кораллар кулга төшерелгән.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 14 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, 12 нче январьда союзниклар авиациясе Триполидан ерак түгел генә Кастель Бенитодагы дошман аэродромына атака ясаган. Бу операция вакытында 14 самолет һавада бәреп төшерелгән һәм 20 самолет җирдә юк ителгән. Союзниклар авиациясе бер самолетта югалтмаган.

Шулай ук дошманның Сус белән Сфакс арасындагы объектлары да бомбага тотылган. Болардан тыш дошманның транспорт колонналарына һәм башка әһәмиятле объектларына бомбалар ташланган. Һәркайда да янгыннар һәм шартлаулар күренгән.

ДЕ ГОЛЛЬ БЕЛӘН ЖИРО ОЧРАШУГА ӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

ЛОНДОН, 14 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Төньяк Африкадагы союзниклар гаскәрләре штабының белдерүен тапшыра. Бу белдерүдә, французларның рәсми вәкиленең әйтүенә караганда, озаклamый Жиро белән де Голльның очрашуы булачагы күрсәтелгән.

АНГЛИЯ БОМБАРДИРОВЩИКЛАРЫНЫҢ ЭССЕНГА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 14 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Англия бомбардировщикларының 14 нче январьга каршы төндә Рурга яңадан һөҗүм ясаганлыкларын хәбәр итә. 12 минут эчендә 100 тонна фугаслы һәм яндыргыч бомбалар ташланган. Башлыча Эссен шәһәре бомбага тотылган.

АНГЛИЯГӘ КАНАДА ГАСКӘРЛӘРЕ КИЛҮ

ЛОНДОН, 14 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, Канададан читтә хезмәт итүче Канада гаскәрләре һәм авиациясе өчен Англиягә яңа өстәмә көчләр килгән. Бу—өч атна эчендә Англиягә килгән һәм берничә мең кешедән торган зур отрядларның икенчесе.

БОЛГАРИЯДӘ КҮПЛӘП КУЛГА АЛУЛАР

СОФИЯ, 14 январь. (ТАСС). Матбугатның язуына караганда, кичә полиция Софиядәге кайбер кафеларда һәм рестораннарда облавалар ясаган. 184 кеше кулга алынган. Аларның бер өлеше Тасос һәм Самофракия атауларына сөрелгән.

АКШ НЫҢ КЫТАЙДАГЫ ЭКСТЕРРИТОРИАЛЬЛЕК ХОКУКЛАРЫН ЮККА ЧЫГАРУ ТУРЫНДА АКШ БЕЛӘН КЫТАЙ АРАСЫНДА ДОГОВОРГА КУЛ КУЕЛУ

ВАШИНГТОН, 14 январь. (ТАСС). АКШ ның дәүләт секретаре Хэлл һәм Кытай илчесе Вэй Дао-мин Кушма Штатларның Кытайдагы экстерриториальлек хокукларыннан ваз кичүләре турындагы договорга кул куйганнар.

ТӨНЬЯК АФРИКАГА АМЕРИКА МИССИЯСЕ КИЛҮ КӨТЕЛӘ

ЛОНДОН, 14 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, якын араларда Төньяк Африкага Америка миссиясе җибәрелүне көтәләр. Бу миссия халыкка ярдәм оештырачак.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

—Беренче алынган саннарга караганда, 1942 нче елны АКШ та 640 миллион тонна күмер чыгарылган. Бу 1941 нче елга чагыштырганда 73 миллион тоннага артык дигән сүз.

—Англиядә 18 яшькә җиткән ирләрне армиягә чакыру турындагы указга кул куелган.

—Албания партизаннары Скрапап провинциясен оккупантлардан азат иткәннәр.

—Һиндстанда «Москва янында немец гаскәрләрен тар-мар итү» дигән картина зур уңыш белән бара. Дәһлидә генә дә өч көн эчендә бу картинаны 6 меңнән артык кеше караган.

—Бельгиянең Антверпен докларында 500 эшче эш ташлаган. Шулай ук Антверпеннан көньякта Шельде елгасындагы бер электр станциясендә дә забастовка булу турында хәбәр итәләр.

—Франциянең Тур шәһәрендә Гитлер агенты Марсель Деага һөҗүм иткән 7 французны җәзалап үтергәннәр.

—Үткән елның 11 ае эчендә Американың һава көчләре барлык сугыш мәйданнарында дошманның 987 самолетын бәреп төшергәннәр. Англия авиациясе 309 самолет югалткан. Шулардан 152 се хәбәрсез югалган.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген—*„Фельдмаршал Кутузов“*. Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Татар дәүләт филармониясе. Менжинский исемендәге клубта бүген һәм 17 нче январьда — *Молдавия дәүләт джазының соңгы ике гастроле.* Кич 8 сәгатьтә башлана.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 17 нче январьда көндез һәм кич—*„Мәрьям“*. Көндезге спектакль 12 сәгатьтә, кичке спектакль 7 сәгать 30 минутта башлана.

Дәүләт циркы. Бүген—*зур цирк тамашасы“*. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген—*„Ильдар“*.

„Электро“ — Америка фильмы—*„Сиңа сокландым“*.

„Унион“—*„Цирк“*.

„Пионер“ көндез—*„Конек-Горбунок“*, кич—*„Георгий Саакадзе“*.

„Чаткы“ — *„Корыч ничек чыныкты“*.

„Кызыл йолдыз“— *„Гроза“*.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27. редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75. промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 616. „КРАСНАЯ ТАТАРИЯ“ һәм „КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН“ издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 83